# Ял сәгатьләрендә

## Сынамышлар

Январьда салкын булса, июль коры һәм эссе була, күзгә кадәр гөмбә чыкмый.
* Январьда кар еш яуса, буран шактый еш булса, июль ае яңгырлы килә.
* Бу айда боз сөңгесе күренсә, уңыш яхшы була.
* Елның беренче ае болытлы булса, икмәк уңмаска мөмкин.
* 14 январьда кар яуса, икмәкле ел була.
* 19 январьда көн аяз икән, җәй коры, болытлы көн булып кар да яуса, җәен явымтөшемнәр гадәттәгечә булып, ел яхшы килә.
* 25 январьда кояш чыкса, кошлар иртә килергә мөмкин, кар яуса, җәй яңгырлы була.
* Елның беренче ае болытлы булса, икмәк уңмаска мөмкин.
* Январь җылы булса, яз соңара. Январь җылы – март салкын.
* Сукыр тычкан оясыннан январьда чыкса, май салкын булыр.

«Шигырьләр илендә»

Өзекләр алынган шигырьләрнең исемен һәм авторынискә төшерәбез.

1.Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул.

2. Күрше белән борыннан
Булмады һич татулык.
Көн саен бер усаллык,
Көн саен бер катылык.

3. Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр,
Иң дәһшәтле утка керәмен;
Шулай була калса, кояшны да
Бүген соңгы тапкыр күрәмен.

4.Шушы яктан, шушы туфрактан без
Китә калсак үзгә бер якка,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр елап озата.



**КЫШКЫ ТАБЫШМАКЛАР**

Мамык юрган, кат-кат сырган,
Үзе суп-суык. (Кар)
***
Каз мамыгын кагына,
Кагына да тузына. (Буран)
***
Тәңкә карлар сибелгән,
Җир ап-акка күмелгән.
Чыршы, каен, имән
Кардан чикмән кигән.
Бу кайчак? (Кыш)
***
Ак мамык кебек,
Ялтырый алмаз кебек. (Кар)
***
Оча – юк канатлары,
Чаба – юк аяклары,
Тышта булса өелә,
Өйгә керсә, җәелә. (Кар)
***
Шома табанлы чана,
Атсыз да алга чаба -
Җитез булса аяклар,
Кулда булса таяклар. (Чана)
***

**Газетаны оештыручы һәм баш редактор:** татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әхмәтгалиева Эльмира Алис кызы
**Редколлегия әгъзалары:** Мифтахетдинова Фирдания Ансар кызы, Шакирова Илүзә Минзия кызы, Шарафетдинова Гөлзада Нуриәхмәт кызы

**Индекс-** 422020

**Адрес:** ТР, Арча муниципаль районы ,Яңа Кырлай авылы, Үзәк урам, 2 йорт.

Январь,2025
№ 1



МБОУ «Ново-Кырлайская СОШ имени Г.Тукай»
МБГБУ «Г.Тукай исемендәге Яңа Кырлай урта мәктәбе»

# ЧИШМӘ БАШЫ

## 2025 ел – Ватанны саклаучылар елы.




Россия Президенты Владимир Путин гаиләләргә ярдәм мәсьәләләре буенча Дәүләт Советында шундый тәкъдим белән чыгыш ясады. Яңа ел тематикасын президент махсус операциядә катнашучылар хөрмәтенә һәм ата-бабаларның батырлыклары истәлегенә сайларга тәкъдим итте. Ел тематикасы хәзерге Россиянең өстенлекләрен чагылдыра – патриотлык, буыннар дәвамчанлыгы һәм Ватанны саклаучыларга хөрмәт. Шунысы игътибарга лаек, Ватанны саклаучылар елы 2024 елда Гаилә елына алмашка килә, һәм бу очраклы түгел. Бу гаилә кыйммәтләре һәм Ватанга героик хезмәт арасындагы тирән бәйләнешне ассызыклый. Демография һәм аналарга ярдәм итү мәсьәләләренә багышланган Гаилә елы киләчәккә нигез салды. Ә Ватанны саклаучылар елы якты һәм мөһим вакыйга булачак, ул әлеге нигезне саклаучыларның казанышларын ассызыклаячак. Ватанны саклаучылар елы 2025-ул календарь датасы гына түгел, ә милли бердәмлек һәм патриотизм символы. Бу яклаучыларга һәм яклауны дәвам итүчеләргә тирән рәхмәт белдерү дә.

# Изгелек кылырга ашык!

Тыныч булсын өчен дөньялар,
Көлсен өчен һәрчак сабыйлар,
Туган җирдән бик тә еракта
Көрәшәләр солдат абыйлар.

Абыйларга җылы булсын дип,
Туган җирнең тәмен тойсын дип,
Тырышалар апа - абыйлар
Рәсем ясый хәтта сабыйлар.

Безнең дә өлеш керсен дип,
Окопларда якты булсын дип,
Ясадык менә шундый шәмнәр,
Алар тиздән барып җитәрләр.

Чын хәйрия ярминкәсе
Уздырабыз мәктәптә.
Акчаларын солдатларга
Җибәрдек без, әлбәттә.













# Мәктәп тормышы

2025-нче махсус ел-Бөек Җиңүнең 80 еллыгы һәм 1945 елның 27 гыйнварында Освенцим үлем лагерен азат итүнең 80 еллыгы елы, аның еллыгында Халыкара Холокост корбаннарын искә алу көне билгеләп үтелә. Бу көн кысаларында тәрбия буенча директор киңәшчесе И.М. Шакирова яшь армиячеләр һәм Җиңү волонтерлары белән берлектә «аклы-каралы дөнья: тәрбия фотосурәтләр аша»дигән түгәрәк өстәл оештырды. Укучылар Холокостның кешелек тарихында иң коточкыч җинаять икәнен белделәр. Чара интерактив күргәзмә күрсәтү белән үрелеп барды. Фашистларның үлем лагеренда кылган коточкыч хәлләрен: җәзалауларын, җинаятьчел медицина тәҗрибәләре үткәрүләрен, крематорийларда терелә̆й яндыруларын белделәр. Иң куркынычы, лагерьдагы тоткыннар арасында балалар да булган. Чара толерантлык мәсьәләләре буенча фикер алышу белән тәмамланды. Мондый чаралар яшьләрдә тарихка хөрмәт һәм кеше тормышының кыйммәтен аңлау тәрбияләргә ярдәм итәр дип өметләнәбез.








# Батырларның даны мәңгелек

**27 гыйнвар - Ленинградны фашистлар блокадасыннан тулысынча азат итү көне**

Бүген Бөек Ватан сугышы барышындагы хәлиткеч вакыйга уңаеннан «Өмет чаткысы» интерактив материалын кулланып класс сәгате узды. Яшь армиячеләр, Җиңү волонтерлары һәм тәрбия буенча директор киңәшчесе И.М. Шакирова җитәкчелегендәге беренчеләрдән булып хәрәкәт лидерлары блокада вакытында ленинградлыларның батырлыгы, ныклыгы һәм патриотизмы, салкын шәһәр тормышы, «тормыш юлы», блокададагы Ленинград балалары турында сөйләделәр. Әңгәмә барышында балалар «Өмет чаткысы» һәм «Ленинград " күргәзмәләре буенча виртуаль экскурсия ясадылар. Тормыш юлы."Җиңү музеенда. Экспонатлар арасында укучылар кыр телефон аппаратын һәм элемтәчеләр файдаланган кыр телефон кабелен күрсәттеләр; е.П. Мерецкова, сугышта катнашучы һәм СССР маршалы к. А. мерецковның хатыны таныклыгы; 1943 елның кышында Ленинград һәм Волхов фронтларының сугыш хәрәкәтләре барышы схемалары. болар барысы да бу уникаль хәрби операциянең хронологиясен кабатларга, аның батыр катнашучыларын һәм данлыклы геройларын күрсәтергә мөмкинлек бирә. «Искра» коткару операциясе, блокада боҗрасын өзеп, йөзләрчә мең ленинградлыга тормыш бүләк итеп кенә калмады, ә бөтен илне рухландырды. Бүген без блокада корбаннарын искә алабыз һәм һәлак













# Мәктәп тормышы

1. Арча шәһәренең 6 нчы урта мәктәбендә профсоюз членнары арасында шашка, шахмат ярышларының финал этабы узды. Шахмат буенча Шарафетдинова Г. Н. 1 нче урынны алды. Котлыйбыз! Киләчәктә дә уңышлар телибез.




Районара шахмат,шашка ярышлары буенча мәктәбебез 3 нче урынга лаек булды һәм грамота белән бүләкләнде.



## 26 гыйнвар - Халыкара Интернетсыз көн

«Өстәл уеннары оазисы»өстәл уеннары турниры 2025 елда Халыкара Интернетсыз көн 26 гыйнварда билгеләп үтелә. Аның максаты-бер генә көнгә булса да виртуаль дөньяда түгел, ә реаль дөньяда игътибарны туплау. Бүген мәктәбебездә тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесе И.М. Шакирова һәм физкультура укытучысы И. З. Шакиров җитәкчелегендә башлангыч сыйныф укучылары һәм ата-аналар арасында шашка буенча турнир узды. Турнирның максаты-укучыларга өстәл уеннарының социаль челтәрләр урынына мавыктыргыч һәм файдалы вакыт үткәрү чарасы була алуын күрсәтү, бу аралашу күнекмәләрен үстерергә, логик фикерләүне, команда рухын һәм укучылар арасында дуслык мөнәсәбәтләрен үстерергә мөмкинлек бирә.











# Белем дөньясында

Икенче юнәлештә дә эш эзлекле тәртиптә барды. Набиуллина С.Р.,Камалиева Р.М.-башлан.кл.укытучылары, ”Россия бөркетләре” берләшмәсе наставниклары катнашында Россия бөркетләре” берләшмәсе эшчәнлеге буенча“Яхшылык җирдә ятмый”дигән проект-дәрес, физика укытучысы Ганеев И.Т. 9 класслар белән үткәргән Физик тәҗрибәләр лабораториясе эшлекле дәрес (“Усеш ноктасы”), биология укытучысы Мифтахова Г.Г., физик тәрбия укытучысы Шакиров И.З.тарафыннан 11 нче класс та Зыян күрүчегә беренче ярдәм күрсәтү (ОБЗР һәм биологиядән интергаль дәресләре;“Алдынгылар хәрәкәте”нең Беренчел бүлек рәисе Шарафутдинова Г.Н., тәрбия биру буенча директор киңәшчесе Шакирова И.М, “Алдынгылар хәрәкәте”нең Беренчел бүлек рәисе урынбасары Сафиуллин Р.Б, “Алдынгылар хәрәкәте”нең лидеры Гайфуллина Р.Р ләр тарафыннан үткәрелгән Балалар инициативасы үзәге эшчәнлеге карап кителде.Мәктәп директоры Хәйруллина З.И кунакларга ”Конфликтны чишү” рольле уены дәрес күрсәтте. Шулай ук икенче төркемдәгеләр дә тарих укытучы Шигапова Г.Х җитәкчелендә музей почмагында булдылар һәм тәрбия эш. буенча директор урынбасары, Зарипова М.Р үткәргән “Без Тукай оныклары” мәктәбебез талантлары белән таныштылар.

Соңгыннан ике төркемгә дә мәктәп эшчәнлеге белән таныштыру өчен мәктәп директорыбыз Хәйруллина Зөлфия Илгиз кызының чыгышы тыңланылды. Эшлекле киңәшмәдән соң кунакларыбызны чәй өстәле һәм матур ял концерты көтеп тора иде.










# Белем дөньясында

30 гыйнвар көнне мәктәбебездә “Белем һәм тәрбия бирү процессында “Алдынгылар хәрәкәте”эшчәнлеге юнәлешләре” темасына директорлар семинары булып узды.

Семинар кунакларны Кечкенә Габдулланың Кырлайга килү күренешен күрсәтү белән башланып китте. Мәктәбебез эчендә семинарда катнашучыларны Г.Тукайның заманча экият геройлары белән очрашу көтеп тора иде.Семинар ике юнәлештә барды.

Килгән кунакларыбызга беренче юнәлештә: 4 класс укучылары белән укытучылары Фатихова С.Д.,Закирова Г.Ш, Мифтахетдинова Ф.А”Йолалар һәм бәйрәмнәр ”проекты кысаларында Пермь өлкәсе Октябрь районы Ишим төп мәктәбе белән дуслык күпере; Балалар бакчасы белән мәктәпнең хезмәттәшлеге темасына ”Белем үрләренә сәяхәт”; химия укытучы Шакирова К.Д. 9 классларда Туфрак тирәлеген билгеләү (химия һәм биологиядән интергаль дәрес, ”Усеш ноктасы” һәм агрокласс эшчәнлегенә дәресләр карадылар.Тарих укытучы Шигапова Г.Х җитәкчелендә музей почмагында, Шарафутдинова Г.Н.-“Алдынгылар хәрәкәте”нең Беренчел бүлек рәисе, Шакирова И.М.-тәрбия бирү буенча директор киңәшчесе оештырган “Ватанны саклаучылар” елы кысаларында “Сталинград сугышы вакыйгалары” на карата квест, Сафиуллин Р.Б. –“Алдынгылар хәрәкәте”нең Беренчел бүлек рәисе урынбасары Гайфуллина Р.Р. - “Алдынгылар хәрәкәте”нең лидерының чыгышлары, тәрбия эш. буенча директор урынбасары, Зарипова М.Р үткәргән “Без Тукай оныклары” мәктәбебез талантлары чыгышлары карап кителде.













# Тату сыйныф серләре

5 сыйныф укучылары һәм әти-әниләре сыйныф җитәкчесе Әхмәтгалиева Эльмира Алис кызы белән берлектә "Тату сыйныф серләре" республика конкурсының район этабында чыгыш ясадылар. Ватанны саклаучылар елына карата күргәзмә оештырылды. Укучыларның әти-әниләр белән берлектә тәрбия бирү буенча директор киңәшчесе Шакирова И.М. һәм сыйныф җитәкчесе Әхмәтгалиева Э.А. җитәкчелегендә башкарылган рухи-әхлакый юнәлештә иҗади проект тәкъдим ителде.













Шигърият сөючеләрне туган, дәүләт һәм чит телләрдә шигырьләр укучыларны "Полиглот" район конкурсы үзенә җыйды.

Укучыбыз Галимҗанов Илназ үзенең яраткан шигырьләрен өч телдә сөйләде һәм 2 нче урын алды. Котлыйбыз! Киләчәктә дә җиңүләр, иҗади уңышлар телибез. Җитәкчеләре Р. И. Рәхимова, И. М. Шакирова



# Спорттагы уңышлар



5 нче сыйныф укучысы Әхмәтҗанов Әмир тренерлар Парфенов Г.И., Соколов М.И. истәлегенә уздырылган бокс буенча XIII традицион ачык регионара турнирда, Казан-Арча командаларының матч ярышында 1 урын, махсус хәрби операциядә һәлак булган, бокс буенча спорт мастерына кандидат Файзрахманов Рөстәм Эдуард улы истәлегенә ачык-шәхси Республика Беренчелегенә оештырылган ярышта 1 урынга ия булды.

Аңа киләчәктә уңышлар теләп калабыз.

## Без – татарлар!

Без – татарлар, газиз халкым
Мирас итеп телен калдырган,
Гәрчә күпләр аны ваткан, каккан,
Ләкин татар телем – сакчы калкан.

Без - татарлар, бай тарихлы халык,
Аны зурлый Тукай, Мусалар,
Шиһабетдин, Риза Фәхретдиннәр
Еникиләр, Хәсән Туфаннар.

Мирас-итеп безгә калдырылган
Сабантуйлар, Каз өмәләре,
Табышмагы, мәкаль, әйтемнәре,
Татар халык әкиятләре.

Милләтемә бик тә рәхмәтлемен,
Күпме хәзинәсен туплаган,
Шушы хәзинәне таркатмыйча
Мирас безгә - алга атларга,
Татар теллелекне сакларга!

*9 нчы сыйныф укучысы*
***Галимҗанов Илназ Илдар улы***

## Күрсәтте безгә сугыш!

42 нче ел – Ат елы
Сугышның кызган елы.
Без дөньяга килгәнбез,
Ат кебек эшләгәнбез.

Китап, дәфтәр дә күрмәде,
Сугыш чоры баласы.
Ә шулай да бик тырышты
Исән калган күбесе.

Кычыткан да, алабута,
Әни пешергән ашлар.
Бер уч ашлык алып кайтсаң
Себергә китәр башлар.

Ите,сөте, май,йомырка,
Барысы да фронт өчен.
Бәйли, сохари киптерә,
Кызганмый бөтен көчен.

Тракторист та, комбайнер,
Авылда калган кызлар.
“Әти” сүзен әйтә алмыйча,
Картаешып баралар.

Сугыш чоры баласына,
Күп сынау бирде язмыш.
Шул сынаулар уртасында,
Үтте бит безнең тормыш

Йөрәкләр һаман да сыкрый,
Исләрдә бит ул һәрчак.
Ач, ялангач бала вакыт,
Чабаталы үсмерчак.

Ачлык күрдек , исән калдык,
Укуны ташламадык.
Кычыткан ашлары белән
Җаныбызны саклыдык.

Гомер узган, хәсрәтләрне,
Коя – коя 80 елларга,
Аяз күкле, имин тормыш,
Бирсен ходай дөньяга.

***Сугыш чоры баласы, ветеран укытучысыбыз Галяветдинова Венера Рәфгать кызы***